Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл Советы

Решение

22.09.2021ел №23

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл жирлегенең Жирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, Түбән Өскебаш авыл жирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл жирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Түбән Өскебаш авыл жирлеге» муниципаль берәмлегенең Жирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» Түбән Өскебаш авыл жирлеге Советының 2014 елның 25 гыйнварындагы 5 номерлы карары (2016 елның 16 декабрендәге 34 номерлы, 2018 елның 21 июнендәге 16 номерлы, 2019 елның 20 февралендәге 4 номерлы, 2019 елның 29 августындагы 19 номерлы Түбән Өскебаш авыл жирлеге Советы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Түбән Өскебаш авыл жирлеге» муниципаль берәмлегенең «Жирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә». 18.1 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

«18. 1. Җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге жир кишәрлекләренең минималь күләме – 1 000 кв.м.

«Шәхси торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге жир кишәрлегенең максималь күләме – 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.»

2.Кукмара муниципаль районы Түбән өскебаш авыл жирлеге Советының 2021 елның 9 июненнән №14 номеры белән кабул ителгән "Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл жирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" карарны көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Түбән Өскебаш авыл жирлеге башлыгы Н.М.Мөхәммәтҗанов